# ПРОЕКТ

## ”Укучыларда коммуникатив, мәгълүмати-аналитик компетенцияләр формалаштыру» юнәлешендә эшләнгән «Р. Фәхреддин хезмәтләрендә халык педагогикасы» авторлык программасы.

**ПРОЕКТНЫ ЭШЛӘДЕ:**
Шайхулова Гөлназ Фаяз кызы
**Проектның фәнни җитәкчесе:** Габидуллина Ф.И.

# Проектның концепциясе

Бүгенге җиһан катлаулы, тиз үзгәрүчән. Шуның белән бәйле рәвештә мәгарифнең дә яңа шартларда яшәргә сәләтле кеше тәрбияләүдәге җаваплылыгы арта бара. Социаль-тарихи һәм мәдәни процессның шундый субъекты булып һәрьяктан камил, рухи яктан үскән шәхес тора. Ул шул мохиттә яшәргә сәләтле булу белән бергә анда актив эшләү күнекмәләренә дә ия булырга тиеш.

“Р. Фәхреддин хезмәтләрендә халык педагогикасы” авторлык программасы гомуми белем бирү мәктәпләрендә өстәмә белем бирү юнәлешендә гамәлгә ашырыла, мәгариф системасының үстерелеш принципларына туры килә. Электив курсларда Р. Фәхреддин мирасын өйрәнү бүгенге көн таләпләренә тулысынча җавап бирә. Әлеге курс программасында Р. Фәхреддин хезмәтләренең, халык педагогикасының тәрбияви әһәмиятенә һәм мәгълүмат ташкынында дөрес ориентлашу, кирәкле информацияне сайлап алу, гомумиләштерү һәм нәтиҗә ясау күнекмәләре формалаштыруга, балаларның кылган эш гамәлләре аша дөрес нәтиҗә ясый алу юнәлешенә өстенлек бирелә.

Өстәмә белем бирү буенча бу программа 7-8 нче сыйныфлар өчен атнага 1 сәгать исәбеннән 35 сәгатьлек итеп, бер уку елына төзелгән.

## Проектның максаты:

Р. Фәхреддин хезмәтләре аша укучыларда әдәп, әхлак, җәмгыятькә караш тәрбияләү

.

# Проектның бурычлары:

- *шәхес буларак үсүләрен формалаштыру:*
- Р. Фәхреддин хезмәтләренә карата кызыксыну уяту;
- Фәхреддин хезмәтләренә һәм халык педагогикасына нигезләнеп, укучыларда кешелеклек сыйфатлары тәрбияләү алымнарын эзләү;
- сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә омтылу, аралашу процессында үз фикереңне тулы, төгәл, аңлаешлы итеп җиткерә белүгә ирешү
- *регулятив уку күнекмәләрен формалаштыру:*
- Р. Фәхреддин һәм татар милли педагогикасы турында булган һәм өйдә өстәмә материаллардан алып килгән белемнәрен билгеле бер эзлеклелеккә салып, гамәлдә куллану

- *Танып белү эшчәнлекләрен формалаштыру:*
- Тема буенча үзеңнең фикереңне булган белемнәреңне файдаланып, дәлилле белү;
- яңа технологияләр ярдәмендә эшләргә өйрәтү

- *Коммуникатив уку күнекмәләрен формалаштыру:*

Укучыларның иҗади көчен, мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен үстерү

# *Ирешү ысулы*

- Авторлык программасы этаплап эшләүгә корылган. I этапта Р. Фәхреддин хезмәтләренең эчтәлеге белән танышу каралган.  II этапта нәсыйхәтләрнең эчтәлеге турында фикер алышу үткәрелә. III этап – практик эш. Р. Фәхреддин нәсыйхәтләре белән бәйләп, теге яки бу темага иҗади эшләр башкару, әдәплелек дәресләре, түгәрәк өстәл янында сөйләшүләр үткәрү дә каралган.

# Ирешу ысулы

**Мәшһүр мәгърифәтче – галим, педагог – Риза Фәхреддин.** (3 сәгать) Р. Фәхреддиннең тормыш юлы, эшчәнлекләре
хакында сөйләшү.

**Әти-әни! Сез гомер бүләк итүчеләр!** (3 сәгать) Р. Фәхреддиннең әти-әнисе турында. Ата-ана турындагы нәсыйхәтләре буенча фикер алышу. Укучыларның үз әти-әниләре турында сөйләүләре.

**Туганнар әдәбе.** (3 сәгать). Дәресләр Р. Фәхрэддиннең туганнары, якыннары, балалары турында сөйләшү, “Туганнар әдәбе” дигән нәсыйхәтләрне уку буенча уздырыла.

**Мәктәп әдәпләре.** (3 сәгать). Олуг галимебезнең белем баскычларына күзәтү ясау, әлеге темага караган нәсыйхәтләрне укып өйрәнү буенча уздырыла.

**Гыйлем.** (3 сәгать). Нәсыйхәтләрне өйрәнү, галимнәребез турында сөйләшү.

**Китап уку кешенең йөзенә нур, күңеленә шатлык китерә...** (3 сәгать) “Китап уку” нәсыйхәтләре, укучыларның
үзләре укыган әдәби китаплар буенча фикер алышу.

**Аллаһ өчен бирәүне яраткан кеше иманның ләззәтен табар.** (Хәдис) - (3 сәгать). “Дуслык әдәпләре” турындагы
нәсыйхәтләр.

**Һөнәр – сәнагать.** (3 сәгать) Нәсыйхәтләрне өйрәнү. Халык педагогикасына күз салу.

**Әхлакый хәзинәләр** (3 сәгать) Нәсыйхәтләрне өйрәнү. Халык педагогикасында әхлак тәрбиясе.

**Начар хәлләр – ямьсез холыклар.** (3 сәгать). Нәсыйхәтләрне өйрәнү

# Тематик бүленеш

| № | Темалар | Сәгать саны |
|---|---|---|
| | Мәшһүр мәгърифәтче – галим, педагог – Риза Фәхреддин. | |
| 1 | Тормыш юлы турында сөйләшү. | 1 |
| 2 | Р. Фәхрэддин турындагы мультимедиа басманы карау. | 1 |
| 3 | Практик дәрес<br>Үрнәк алырлык шәхесләребез бар! | 1 |
| | Әти-әни! Сез гомер бүләк итүчеләр! | |
| 4 | Р. Фәхрэддиннең әти-әнисе хакында. | 1 |
| 5 | Ата-ана турындагы нәсыйхәтләре буенча фикер алышу | 1 |
| 6 | Практик дәрес.<br>Укучылар әти-әниләре турында иҗади эшләр язалар. | 1 |
| | **Туганнар әдәбе.** | |

| | | |
|---|---|---|
| 7 | **Р. Фәхрэддиннең туганнары, якыннары, балалары турында сөйләшү** | 1 |
| 8 | “Туганнар әдәбе” дигән нәсыйхәтләрне уку | 1 |
| 9 | Практик дәрес “Гаилә кодексы” темасына түгәрәк өстәл янында сөйләшү. | 1 |
| | Мәктәп әдәпләре. | |
| 10 | Олуг галимебезнең белем алу баскычлары | 1 |
| 11 | **“Мәктәп әдәпләре” нәсыйхәтләрен уку** | 1 |
| 12 | **Практик дәрес “Син, мәктәбем, белем учагы” темасына иҗади эш.** | 1 |
| | Гыйлем. | |
| 13 | “Гыйлем – нур, наданлык – хур” темасына әдәплелек дәресе үткәрү | 1 |
| 14 | **“Гыйлем” нәсыйхәтләре. Галимнәребез турында. (Ш. Мәрҗәни, К. Насыйри, Габдерәхим Утыз Имәни)** | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| **15** | **Практик дәрес “Гыйлемлек – бетми торган хәзинәдер...”темасына инша язу.** | **1** |
| | Китап уку кешенең йөзенә нур, күңеленә шатлык китерә... | |
| **16** | “Китап уку” нәсыйхәтләре | **1** |
| **17** | Түгәрәк өстәл янында. “Соңгы вакытта укыган китабым” | **1** |
| **18** | **Практик дәрес**<br>**“Яраткан китабым” исеме астында иҗади бәйге уздыру. Укучылар үзләре яратып укыган китапны нәни китапчык рәвешендә, рәсемнәр белән бизәп ясыйлар.** | **1** |

| | | |
|---|---|---|
| | **Аллаһ өчен бирәүне яраткан кеше иманның ләззәтен табар.** | |
| **19** | Халык педагогикасы “дуслык” турында. | **1** |
| **20** | “Дуслык әдәпләре” турындагы нәсыйхәтләр. | **1** |
| **21** | Практик дәрес “Яман юлдаш – тимерче уты кебек. Бер вакытта очкыны төшеп киемеңне яндырыр” хәдисе буенча фикер алышу.. | **1** |
| | Һөнәр – сәнагать | |
| **22** | Һөнәр – сәнагать. Нәсыйхәтләрне үзләштерү. | **1** |
| **23** | Татар халык педагогикасында хезмәт тәрбиясе. | **1** |
| **24** | **“Кешене туйдыручы – һөнәр” темасына тәрбия сәгате үткәрү.** | **1** |

| | | |
|---|---|---|
| | **Начар хәлләр – ямьсез холыклар** | |
| **28** | Начар хәлләр – ямьсез холыклар. Нәсыйхәтләрне өйрәнү | **1** |
| **29** | Отышлы уеннар турында. | **1** |
| **30** | **Практик дәрес “Җир йөзендә тәкәбберләнеп йөрмә. Чөнки син җирне тишә алмассың, буең да тауларга җитмәс.” Хәдисе буенча сөйләшү үткәрү** | **1** |

| | | |
|---|---|---|
| | **Рухи мирас – хәзинә ул** | |
| **31** | Р. Фәхреддин музеена сәяхәт. | **1** |
| **32** | “Рухи мирас-хәзинә ул” темасына проектлар әзерләү. | **1** |
| **33** | Проектларны яклау дәресе. | **1** |
| **34** | Проектлары буенча презентация ясау. | **1** |
| **35** | **Йомгаклау дәресе.** | **1** |

# *Көтелгән нәтиҗә*

Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләре аша укучы тормыш фәлсәфәсенә төшенә, аның фикерләү сәләте үстерелә, коммуникатив эшчәнлеге арта. Ә иң әһәмиятлесе – укучыларым әдәпле, әхлаклы, кешелекле булу сыйфатларын үзләрендә булдыралар.

# *Кулланылган әдәбият*


- Балаларга нәсыйхәт. Төз: Ә. Хәйри, Ә. Мадьяров. – Казан, 2006. – 259 б.
- Балаларга үгет-нәсыйхәт. Н. Ибраһимов, К. Бикчәнтәев. – Казан, 2001. – 61 б., 89 б., 54 б.
- Иманлы төбәк җәүһәрләре. Роза Абзалова-Сәлманова. – Казан: “Сүз” нәшрияты, 2008, - 67 б.
- Татар милли педагогикасы. Р. Х. Шәймарданов, Р. Г. Сибгатуллин,
- Алабуга, 2004, - 141 б.
- Әхлак дәресләре. В. Казыйханов, Яр Чаллы, 1998, - 170 б., - 128 б.